

Рәсимә Гарифуллина

# МИНЕМ КУЛЛАР — СИНЕҢ КУЛДА



Шигырьләр, поэма

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)—5
Г 22

**Гарифуллина Рәсимә**

Г 22 Минем куллар – синең кулда: Шигырьләр, дастан. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. – 95 бит.

Җыентыкта авторның лирик-фәлсәфи шигырьләре һәм «Ак Сарайда серләр бар» дигән поэмасы урын алды.

ISBN 5-298-04125-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Гарифуллина Рәсимә, 2005

## Минем куллар – синең кулда

Учларыма язылгандыр язмышларым –
Китәр җирем, барыр юлым.
Аңлый алсаң укып кара, өмет белән
Сиңа сузам ике кулым.

Йөрәгемнең ярсулары күчкән анда,
Укып кара һәрбер сырын.
Юлы саен шашкын хисем, сөюләрем,
Анда минем яшәү серем.

Язылгандыр үткәнем дә киләчәгем,
Шатлыгым һәм борчуым да.
Язмышларым учларымда – укып кара,
Минем куллар – синең кулда.

Тормыштагы ашкынуым, дәртем, гамем,
Югалтуым-табышларым.
Минем куллар – синең кулда, кавыштырсын
Гомерлеккә язмышларны.

## Мәхәббәттән тора бөтен нәрсә

Әнисенә иркәләнеп колын үсә,
Ат ялларын җилфердәтеп җилләр исә.
Кабатланып тора тормыш – яшәү серле,
Буыннардан буыннарга күчә-күчә.

Акчарлакның сыенырга ярлары бар,
Чишмәләрнең көмеш чыңлы җыры тынмый.
Инешләрнең назлый торган таллары бар,
Сандугач та үз баласын тыңлап туймый.

Мәхәббәттән тора җирдә бөтен нәрсә,
Җир-анадан яралганбыз син дә, мин дә.
Әниләрнең яратуын, назын тоеп,
Күкрәк сөтен татып үсә җирдә кем дә.

## Тамчылар бүләк итәм

Тәрәзә артында яңгыр ява –
Язгы тамчыларның үз көе.
Чык син әйдә, чык син урамга!
Син дә яңгыр көенә бие.

Учларыма җыям тамчылар,
Кулымдагы тамчыларны эч!
Онытылыр борчу-сагышың,
Йөрәгеңә тулыр кайнар хис.

Учларыма җыеп тамчылар
Язгы яңгыр бүләк итәрмен.
Кал бүгенгә минем янымда,
Иртәгесен генә китәрсең.

## Канатларда өмет

Акчарлактан канат алдым,
Күтәрелдем күкләргә.
Җирдән гарешләргә киту
Эләкми ул күпләргә.

Дулкыннардан ярсу алдым,
Дәрьялардан – тирәнлек.
Яңгыр булып җирне юдым,
Яктырсын дип тирәлек.

Ак болытлар өрфиясе
Кунды ике иңемә.
Аккош тугрылыгы белән
Очтым хыял күгенә.

Каурый каләм белән яздым
Йөрәгемнең хисләрен.
Җилләр булып урап йөрдем
Якты урман эчләрен.

Офыклардан шәфәкъ алдым,
Нурлары йөзләремдә.
Канатларым күтәрделәр,
Юк, җирдә түзмәдем лә.

Янәшәмдә кояш уйный,
Бөдрә каурый болытлар.
Канатлыларга күкләр тиң,
Канатларда өмет бар.

## Соңгы кар

Күбәләкләр оча, күбәләкләр...
Карлы күбәләкләр – соң кабат.
Күбәләкләр төсле оча-оча,
Хисләреңне пакьлә һәм яңарт!

Күбәләкләр оча, күбәләкләр...
Кайнар биткә кунып юк була.
Ә син, дустым, язны кочар өчен,
Килер язларыңнан җан сора.

## Мин яратам сине

Мин яратам сине, мин яратам,
Ул башкача мөмкин түгел дә.
Сиңа булган сөю, якты хисләр
Җырлар булып ургый күңелдә.

Мин яратам сине, сөйгән ярым,
Бу башкача мөмкин булалмый.
Сөйгән йөрәк кенә шулай ярсый,
Януларны минем ул аңлый.

Мин яратам сине, гомер буе
Йөрәгемдә йөрткән серем бу.
Сөюемне шушы җырга салып,
Серләремне ачкан көнем бу.

Мин яратам сине, бик яратам,
Ул башкача мөмкин түгел лә.
Йөрәгемдә туган якты хисләр
Моңлы җырлар булып түгелә.

# Бары сөю...

Үтәр дә китәр гомерләр,
Калыр маллар, олы даннар,
Калыр дөнья байлыклары –
Шулай киткән патша-ханнар.

Үтәр дә китәр гомерләр,
Сизелми дә фанилыкта.
Барсыннан да өстен калыр
Бары сөю – син онытма!

Мал биреп тә, дан белән дә
Табалмыйсың бер мизгелен.
Баеткан да, зурлаган да,
Яшәткән дә – шул сөюең.

Үтәр дә китәр гомерләр,
Аккан сулар төсле шаулап.
Бизмәннәргә сала тормыш,
Яхшы-яманнарын барлап.

Язмышыңны уйната ул –
Яшен төсле чатнап китә.
Өмет сүнә, дуслар кача,
Яшәүләргә гамең бетә.

Мал таралган, күңел сына,
Күзләреңнең нуры уңа.
Шул чагында мәхәббәтең
Синең юлга каршы чыга.

## Алларыма алма салдың

Алларыма алма салдың,
«Яратам сине», – дидең.
Алмадым алмаларыңны,
Үзеңә кире бирдем.

«Бул минеке, сөям сине,
Багалмам минем», – дидең.
Сөймәгәнне пар итмиләр,
Шуңа да кире бирдем.

Алларыма алма салдың,
Мәхәббәтең сиздереп.
Алмадым алмаларыңны,
Яратмавым белдереп.

Алма кебек яр булсаң да,
Кире кактым мин сине.
Алмадым алмаларыңны...
Һәркемнең дә үз тиңе.

## Синең ярда

Син калган ярларда – өметләр,
Чәчәкле тугайлар, болыннар.
Тик миннән аера ул ярны
Дулкыны ярсыган упкыннар.

Син калган ярларда – хыяллар,
Татлы һәм шатлыклы көннәрем.
Тик мине ул ярдан аера
Йолдызсыз һәм айсыз төннәрем.

Син калган ярларда – бәхетем,
Язларым, җәйләрем, көзләрем.
Упкыны уелган, дулкыны шаулаган –
Син калган ярларда күзләрем.

## Үбим әле

Үбим әле күзләреңнән,
Гел сөеп карасыннар.
Зәңгәр дулкын төсле уйнап,
Ихластан яратсыннар.

Ике колагыңнан үбим,
Пышылдап серле генә.
Яман сүз ишетмәсеннәр,
Сөйсеннәр мине генә.

Маңгаеңа төшеп торган
Чәчләреңнән иркәлим.
Синең көчле кулларыңны
Юк бит әле үпкәнем.

Үбим әле, авыр чакта
Зур терәк булган өчен.
Йөрәкне йөрәккә куеп
Яшәгән еллар өчен.

* * *

Өзелә үзәк,
Миңа син кирәк.
Иңнәрең булсын
Тормышта терәк.

Яшәтә өмет,
Боекмый күңел.
Гел сине көтә,
Өметсез түгел.

Тормышта һәрчак
Миңа син кирәк.
Бул миңа терәк,
Янмасын йөрәк!

* * *

Чүлдәге бер йотым су күк,
Синең назлы карашың.
Җаннарны назлап эретә,
Шуннан да хәл аласың.

Учактагы ялкын күк син,
Үз итеп елмайсаң да.
Аралар җылынган төсле,
Үзең ерагайсаң да.

Сөюләр чикле булмыйдыр,
Салынмый бизмәннәргә.
Сабырлык бир җаннарына
Ялгызы түзгәннәргә,
Кавышу бир гашыйкларга,
Ихластан сөйгәннәргә.

* * *

Мин сине кичерә алмыйм,
Башканы сөйгәнең өчен.
Яшәгәнгә куке кебек
Аңламыйча сөю көчен.

Мин сине кичерә алмыйм,
Хисләреңне туккән өчен.
Мәхәббәтне ваклый-ваклый,
Җиде ятлар үпкән өчен.

Мин сине кичерә алмыйм,
Сөюеңне җуйган өчен.
Күбәләктәй чәчәк саен
Матур эзләп кунган өчен.

Мин сине сөя дә алмыйм,
Юк күңелдә үпкә-үчем.
Йөрәгемнән куам сине,
Хыянәт иткәнең өчен.

...Тоймый яшә сөю көчен,
Уянмасын сүнгән хисең.

# *Кайтаваз*

> Еракларданиңә кайтаваз:
> – Сине, – диеп, – минсез кем яклар?
>
> *Гөлнур Әхмәдуллина*

Бер кисәтү төсле кабатлана:
– Минсез калгач, сине кем яклар?
Чулман өсләрендә кайтавазың:
– Ялгышлардан, бәгырь, кем саклар?

Сагынулардан сулып мин кычкырдым:
– Аерылуга ничек түзәсең?
Кайтавазың әрнеп җавап бирде:
– Нигә болай үзәк өзәсең?

Кайтавазың чатный яшен булып:
– Нигә сүнде безнең учаклар?..
Телеп үтә йөрәк бәгыремне:
– Ялгызлыктан безне кем саклар?

...Дулкын төсле шаулап яңадан
Кире кайтсын иде яшь чаклар.

* * *

Тәнем белән түгел,
Җаным белән
Сиңа тартылам һаман.
Ышан!
Яшьлектәге сыман
Көтәм,
яратам,
янам...

* * *

Икебез дә, берни аңламыйча,
Сөю аланына кергәнбез.
Без соң ничек моңа кадәр аерым,
Ялгыз яшәүләргә түзгәнбез?

Икебез дә утлы йомгак төсле
Кушылдык та ялкын дөрләде.
Сөю аланында җан яралды,
Зәңгәр күзле гөлләр көнләде.
...Ярый әле ятлар күрмәде.

* * *

Нигә пыскып яшисең син,
Сүнеп барган учак төсле?
Күзләреңнең төссезлеге
Салкын булып җанга күчте.

Нигә ялгыз яшисең син,
Шашып сөяр көннәр барда?
Яшен булып яшьнәр чакта
Һәм ургылып дулкыннардай.

Ялкынланып дөрләмисең,
Сүнеп барган учак төсле...
Янып сөяр көннәр алда.
...Яшел яфрак җиргә төште.

# Очрашу

Сабантуй мәйданнарында
Очрашты күзләр күзгә.
Зарыккан йөрәк ялкыны
Комачтай кучте йөзгә.

Сабантуй мәйданнарында
Көрәш, җыр-моң, тамаша.
Күздән күзне алалмадык,
Сагынганбыз лабаса.

Шатлыктан йөрәк ялкыны
Очкынлап уйный йөздә.
Эретә җанны җылысы,
Бәхетле икебез дә.

Син дә, мин дә сүзсез калдык,
Мәйдан да тынды төсле.
Барсы да йөрәкләр серен
Тын гына тыңлый төсле.

Күзгә-күз караган килеш
Сөйләштек сүзсез генә.
Сабантуй мәйданнарында
Әйтерсең лә без генә.

Тоташты йөрәккә йөрәк
Очрашып мәйданнарда.
Бөтереп өермә хисләр
Кушылды җаннар җанга.

Янәшәдә ятлар иде,
Син дә, мин дә – парлылар.
...Күзләр – күздә, җаннар – җанда:
Мәйданнарда калдылар.

# Сине эзләдем

Мин сине бик сагындым да
Тугайлардан эзләдем.

Син булгансың икән, бәгърем,
Зәңгәр гөлнең күзләре.

Гөл күзендә тамчы күргәч
Кызгандым да өзмәдем.

Синең күз яше дип уйлап,
Алларыңа тезләндем.

Чык тамчысы булгансың бит,
Белмәдем шул, белмәдем.

Болытны син дип уйладым,
Кулъяулыгым болгадым.

Шифа яңгыр булып җиргә
Яварсың дип уйладым.

Бөдрә талларга таянып,
Серләремне сөйләдем.

Талда сайрар кош булгансың,
Ишетмәдем көйләрең.

Чәчләреңнән сыйпаган күк
Сыйпадым гөл керфеген.

Гел янымда булгансың бит,
Минем алтын бөртегем.

## Күңелеңдә урын алдым

Күңелеңдә урын алдым
Танышың булып кына.
Исләремә гел төшәсең,
Сагышым булып кына.

Яннарыңа килим әле,
Ярату булып сиңа.
Яшәр идек ике таныш,
Гашыйклар булып кына.

## Язмышлар – дулкында

Яр өсләре киртләч-киртләч –
Агыйдел кыялары.
Агыйдел кыяларында
Карлыгач оялары.

Су өсләре дулкын-дулкын –
Айкала дәрьялары.
Дулкын өсләрендә – язмыш.
...Буталды дөньялары.

## Һәркемнең үзенеке

Төннәр айны сагыналар,
Көннәр кояш нурларын.
Төннең ае, көн кояшы –
Җырланмаган җырларым.

Йолдызлар төнгә табына,
Көн – кояш яктысына.
Һәркемнең дә үз яртысы
Үзенең яртысына.

Әмма айсыз һәм кояшсыз
Яшәү мөмкин түгел лә.
Йолдызлар төсле яктырып,
Җырлар туа күңелдә.

Төннәр айга табыналар,
Көннәр – кояш нурына.
Йөрәктә бар үз урының –
Күчтең инде җырыма,
Әйләндең җан җылыма.

## Беләсеңме?

Сулаган сулышларыңны
Тоеп яшим,
Беләсеңме?
Син дә минем кебек янып,
Минем кебек көясеңме?

Сулаган сулышларыңа
Торып идем,
Беләсеңме?
Син дә бөтен җаның-тәнең
Белән мине сөясеңме?

Синең өчен җаным ярып
Бирәсемне
Беләсеңме?
Син булганга гына мин бар,
Беләм синсез үләсемне.

* * *

Тышта суык бүген, наратлар
Көязләнеп җилгә басканнар.
Яшел энәләрен үткерләтеп,
Яңа кардан алка асканнар.

Ак каеннар, җилдә сыгылып,
Соңгы яфракларын очыра.
Тагын бер көз калды тарихта.
...Җил кагылды яфрак очына.

## Алмалар коелды

Алмагачлар чәчәк аткан иде,
Вәгъдәләштек матур язларда.
Җылы язлар яктылыгы аша
Эредек без сөю-назларда.

Алсуланып, сусылланып пеште
Шаһит алмагачның алмасы.
Икәүләшеп көттек бит без сине
Кайтыр, онытмас дип вәгъдәсен.

Алмагачлар алма койды инде,
Ерак калды якты язлар да.
Үтәлмәгән вәгъдәң төсле синең,
Сусап яшим сөю-назларга.

## Үзем белән үзем

Үзем белән үзем, күзгә-күзем,
Көзгеләргә карап серләштем.
Серләремне чиштем яшермичә,
Үзем белән үзем сөйләштем.

Көзгеләргә төшкән чагылышта
Ялгызлыгым белән киңәштем.
Каерылган канатымны күреп,
Парлыларга карап көнләштем.

Йөрәк янулары басылмый шул,
Үзең белән үзең сөйләшеп.
Яшерен серне сөйләп булмаган күк,
Ялгызлыкны булмый бүлешеп.

# Хыял бакчасы

Хыялларым, миңа буйсынмыйча,
Үземне дә узып киткәли.
Яңа гасырларга ашкыналар
Еллар аша кичеп, үтәли.

Хыял дөньям минем гөлләр иле –
Алсу, зәңгәр, җете кызыллар.
Чәчәк аткан дуслык бакчасы –
Ромашкалар, гөләп, розалар...

Мин сезгә дип гөлләр утыртам бит.
Шау чәчәктән йортым нигезе.
Саф хисләләр генә яши монда,
Гөмбәзендә кояш, күк йөзе.

Бөтен җиһан килсен, кунак итәм,
Хыял бакчасында иркенлек.
Кинәнеп бер ял итегез сез дә,
Кардәшләрем, телим иминлек.

Әнә шундый минем хыялларым,
Гасырларны кичә үтәли.
Меңнәр хыялланган дөнья төзим,
Ямянлыкның юлын киртәлим.

Хыял дөньясында җаннар садә,
Залимлеккә юл юк биредә.
Мин яратам сезне, җирдәшләрем,
Һәм хыялга дәшәм бүген дә.

## Күңелдә яз

Кеше күңелендә һаман шулай:
Кичә генә әле яз иде...
Җәйге болыннарны, көзге сары
Сукмакларны бүген кар күмде.

Гомер уза, күңелләр картаймый,
Унсигездә кебек гел үзем.
Гел язларда гына яшәр идем,
Бик яратам мин бу җир йөзен.

Шатлыклары... түгел, кайгысы да,
Яз аенда яуган кары да,
Көзен чәчәк аткан чияләр дә –
Минекеләр бары, бары да...

## Яз – халәтем

Тышта әле язга ерак, ерак –
Йөрәк ярсып язга ашкына.
Күңелләрдән җылы ташып аша.
Баксаң, тышта салкын март була.

Мин гел шулай, хыялларым аша
Язны якынайтам ел саен.
Мөмкин булса әгәр һәрбер язның
Чиксез итәр идем һәр аен.

Мин язларга гашыйк бала чактан,
Тоташ умырзая күңелем.
Ел әйләнә җанда кояш уйный,
Яз – халәтем, назым, ирегем.

# Төнге тынлык

Мине төнге тынлык тарта,
Төнге җилләр сер сөйли.
Җидегән йолдыз җем-җем килә,
Ачы буран җыр көйли.

Җил буласым килә бүген,
Әйләнәсем Җир шарын.
Шатлансам да, борчылсам да,
Гел янәшә моңнарым.

Күкләрне айкап очыйммы,
Тузыныйммы ду итеп?
Бураннан җирне арчыйммы,
Кояш булып нур сирпеп?

Төнге тынлык сарыла да
Куенына суыра.
Буранлы төнне яктыртып,
Күктән йолдыз коела.

Җиһанда мин бер кисәкчек,
Җил дә түгел, буран да.
Буранга битемне куеп
Басып торам урамда.

## Киңәш

Бик күпләр киңәш бирәләр:
Төннәрнең дә ае бар,
Яшьлек үтәр, үкенерсең,
Соңарырсың, сөеп кал!

Сөеп-сөелеп кала бел –
Йөрәкнең ташкын чагы.
Хисләр уртак таша алса,
Аннан ни кирәк тагы?

## Юкка гына тырыштылар

Каралтырга теләделәр,
Акка төрелгән күңелне.
Кара болыт капласын дип,
Кояш елмайган күгемне.

Суытырга теләделәр,
Сиңа булган хисләремне.
Айсыз, йолдызсыз итәргә
Сине көткән кичләремне.

Яман сүзләр очты уктай,
Тиргәделәр, орыштылар.
Мин барыбер каралмадым,
Юкка гына тырыштылар.

Барысын да җиңә алды,
Мәхәббәттән көчлесе юк.
Балдан татлы, сөттән дә ак –
Чын ярату төслесе юк.

* * *

Бер сүздән дә күңел кайта икән,
Сөюләрне юып ала икән.
Бер яман сүз, кырыс караш хәтта
Төзәлмәслек яра сала икән.

Авыр сүзләр кылыч төсле кисә,
Күкләр елый төсле бу минутта.
Кирәк миңа синең җылы сүзең,
Ялгыз җаным өтелмәсен утта.

Таралсыннар борчу-сагышларым,
Арала син мине ялган сүздән.
Бул янәшә, якты карашың да
Саклый ала мине яман күздән.

* * *

Кайчакта кышлар да җылыта,
Чиләдәй җәйләре суыта.
Кайчакта язларда көз килә,
Көзләрда яз булып наз иңә.

Кайчакта ак кышлар, сөрем күк,
Караңгы пәрдәгә урала.
Кайчакта яп-якты язлар да
Көзләрдә адашып югала.

Җәйләре җаннарны җылытсын,
Кышлары бары тик ак булсын,
Шатлыкка төренсен киләчәк,
Сагышлы минутлар аз булсын!

## Ялгышу

Бу дөньяның фанилыгын,
Мәңгелекнең бакыйлыгын
Аңламыйча ялгышабыз.

Фанилыкны «бакый» диеп,
Гомер бакый байлык сөеп,
Без – адәмнәр – ялгышабыз.

## Белмәделәр

Серле идем –
Саклый белдем түкми-чәчми.
Сер кадере –
Серне йөртү әйтми-дәшми.

Керсез идем –
Нахак белән керләделәр.
Сөйләделәр,
Яшьлегемнән көнләделәр.

Тиңсез идем –
Гөнаһлыга тиңләделәр.
...Эчем тулы ут икәнен белмәделәр.

# Төнге күбәләк

Утка очкан күбәләктәй,
Якты эзләп килдеңме?
Назга сусаган җаныңа
«Җылы табам» дидеңме?

И гомерсез төн кунагы,
Син дә шундый язмышта.
«Кире кактың» дип үчләшмә,
Күбәләк күк ялгышма!

Минем дә бит йөрәгем бар –
Уела да, әрни дә.
Мәхәббәттән кала аны
Җиңә алмый берни дә.

Күбәләк тә утка очып
Өтә ефәк канатын.
Аһ, ялгыштың, төнге кунак,
Канатыңны канаттың...

# Юлда

Ерак башкалага таба
Поезд юл алды.
Хәтер йомгагымның бүген
Очы чуалды.

Һәркемнең дә үз кулында
Үз язмышлары.
Үз шатлыгы һәм борчуы,
Үз ялгышлары.

Берәү таба, берәү җуя
Бәхет уймагын.
Берәү чорный, берәү сүтә
Уйлар йомгагын.

Тайга урманнары аша
Поезд җилдерә.
Аннан алда, канатланып,
Уем йөгерә.

Тәгәрмәчләр җырлап бара
Бәхет турында.
Хыялларым старт алган
Тормыш юлында.

Ни тыңласаң, шуны сөйли
Җилләр тавышы.
Каеннарга сарылып кала
Йөрәк сагышы.

Хыял белән чынбарлыкның
Соңгы ярышы.
Үткәннәрдән киләчәккә
Китеп барышым...

# Мөмкинме соң?

Шагыйрь булып кына туу мөмкин
Чишмәсеннән зәм-зәм су эчкәч.
Сандугачлар җыры моң тулып
Табигатьтән җаныңа күчкәч.

Һәрбер нәрсә шигырь сөйли монда,
Каеннары – җырчы нечкә бил.
Яңгыр тыпырдавы көй чыгара,
Мандолина тарта көзге җил.

Канат бирә, илаһи хис өсти
Әрәмәдә кошлар тавышы.
Үзәкләрне өзеп, өтеп ала
Кирәмәттә таллар сагышы.

Шагыйрь булып кына яшәп була,
Чишмәләрең җырлап акканда.
Баш очында ак болытлар йөзеп,
Алсуланып таңнар атканда.

Ана сөте белән иңгән бит ул
Тамырларга безнең шагыйрьлек.
Йөрәк каны белән язып иңгән
Курку белмәс көчле гаярьлек.

Табигатьнең төсен, бизәкләрен
Күчереп алып яза каләмем.
Сират күпереннән үтүгә тиң
Шагыйрьлектә кылган гамәлем.

# *Көч бир миңа!*

Дуслар этлегеннән сакла, язмыш,
Дошманнарны читләп үтәрмен.

*Әхмәт Саттар*

Дуслар дошманлыгын күрсәтмәче,
Дошман этлегеннән курыкмыйм.
Дошманымнан шәфкать өмет итмим,
Дуслар нәфрәтенә юлыкмыйм!

Дуслар хыянәтеннән саклачы,
Тугрылыклы дуслар бик кирәк.
Дошманымны читләп үтмәм һич тә,
Дошманымнан үзем көчлерәк.

Ләкин дуска кулым күтәрелмәс,
Бер канатым сынар аңарсыз.
Чын дусларын югалтканнар, беләм,
Минем кичерешне аңларсыз.

Дусны кичерерлек көч бир миңа,
Күтәрерлек «дуслар» этлеген.
Көч бир миңа, Раббем, салдырырга
Ялган дусның төлке битлеген.

Хәтерләр бер калса, кайтарылмый,
Тешләп булмый, якын бит терсәк.
Дусны дошман белән бутамаска,
Ялгышмаска туры юл күрсәт!

# Язмыш язылганча булсын

Шатлыкның да, борчуның да
Тиешлесен бүген бир!
Соңга калып, эзәрлекләп
Йөрерлек булмасын гел.

Бүгенгесе бүген килсен,
Иртәгегә калмасын.
Узганнар өчен борчылып
Үртәлергә язмасын.

Сөенечләр бер килер дип,
Көтеп узмасын көннәр.
Сөекле икәнбез инде,
Назларда үтсен төннәр.

Язмыштан язган сынаулар
Килсен тиеш минутта.
Соңга калган үкенүләр
Салмасын ялкын-утка.

Качып котылырлык түгел,
Язылганны күрәбез.
Язмыш язылганча булсын –
Бер яшәп, бер үләбез.

## Бәхетле буласым килә

Бәхетле буласым килә,
Иркәләп сөясем килә.
«Син минеке,
Мин синеке
гомергә» диясем килә.

Күкләргә очасым килә,
Җиһанны кочасым килә.
«Мин бәхетле,
Син бәхетле
гомергә» диясем килә.

## Карама елмайганга

Кайгыларым таудан да зур,
Карама көлгәнемә.
Күз яшемне эчкә йотып
Елмая белгәнемә.

Ялгызлыгым таудан авыр,
Карама елмайганга.
Керфегендә чык, дисездер,
Күрсәтми елаганга...

# Беркем кагылмаган

Офыкларда якты кояш уйный,
Сүнәр өчен шәфәкъ кабынмаган.
Үләннәрдә энҗе чык җемелди,
Мөлдерәмә, беркем кагылмаган.

Зәңгәр һаваларда рәшә уйный,
Арыш башаклары серкәләнә.
Басу өсләрендә ак томаннар
Рәшәләргә кунып иркәләнә.

Һаваларны ярып аккош уйный,
Каерылмас микән бер канаты?
Аккош кебек ап-ак күңелләрдә
Сүнмәс өчен туа чын ярату.

Болыннарда җиләк тәлгәшләре
Пешеп тора, өзеп алынмаган.
Сөю кабынганда кемнәр генә
Сагыш учагына салынмаган?

Якты иртә, таңнар туган сәгать,
Табыласы әле табылмаган.
Йөрәкләрдә сөю туып килә,
Керләнмәгән, беркем кагылмаган.

## Парлы толымнар

Озын кара чәчләремне
Салдым икегә бүлеп.
Парлы бәхетләр теләдем,
Парлы толымнар үреп.

Парлы-парлы толымнарым
Синең белән мин идем.
Бәхетләрем пар булсын дип,
Парлы толымнар үрдем.

Толымнар күк озын булсын
Без үтәсе юл бергә.
Гел янәшә барсак иде,
Аерылмыйча гомергә.

Беркөн иртән назлы куллар
Толымнарым таратты.
Гомергә бергә булырга
Йөрәк белән яраттым.

## Кичермим...

«Минеке инде ул», – диден дә
Син мине бәхеттән аердың.
Аердың...
Нигә соң канатым каердың,
Гомергә ялгызым калдырдың,
Йөрәгем яндырдың?
Яндырдың...

«Минеке инде ул», – диден ник?
...Мин түгел, син мине сөйдең бит.
Мин ялгыз.

Күрәм лә тормышта син парлы.
Парың бар, ярың юк.
...Барыбер моң-зарлы.

Канатлы булып та,
　　канатсыз кош сыман,
Очалмый яшисең.
Талпынма!
Күкләргә синдәйләр ишме соң?

«Минеке инде ул», – дидең дә
Син минем йөрәгем яндырдың.
Яндырдың...
Мәкерле җәтмәңә ауладың,
Син ялган ышаныч яуладың.
Арага кердең ник?
Сөекле ярымнан аердың.

«Минеке инде ул», – дидең дә
Мәңгелек газапка ташладың.
Сагышка уралды башларым,
Йөрәктән тамадыр яшьләрем,
Ничекләр яшәрмен?
Нишләрмен?

Ә үзең?..
Миннән дә ныгырак көясең,
Син мине әле дә сөясең.
Кичермим,
Яшисең сөюдә алдашып.
Йөрәкне куйсаң да алмашып,
Барыбер төзәлмәс ярасы.
Юк аның дәвасы.
Кичермим...

# Гомер атында

И гаҗәп тә гомер, һаман чаба,
Кая дип соң болай ашыга?
Әле генә, янар язлар булып,
Яшьлек чыккан иде каршыга.

Балалар да, багалмалар кебек,
Куанычка булып үскәннәр.
Кая дип соң болай чаба гомер,
Ни арада еллар үткәннәр?

Ун, егерме, утыз, кырык, илле...
Кая дип соң болай ашыга?
Кичә генә сикереп менгән идем
Бу гомернең гаярь атына.

Юртак атлар сыман чабып килү –
Дөнья аргамагы тезгенсез.
Ат ялында җилләр уйнап кала,
Чаба гомер, чаба түземсез.

И гаҗәп тә гомер, һаман чаба,
Нәрсәгә дип болай ашыга?
...Гомер чатларыннан ярсып чабып,
Яшьлек чыгар төсле каршыга.

# Олы булып яшим

Анадан бала күп туса,
Олысына көч була.

*Халык җырыннан*

Мин олысы идем биш бөртекнең,
Булдым иң беренче куаныч.
Әти-әниемнең чын шатлыгы,
Иң тәүгесе, иң зур юаныч.

Беренчесе идем биш бөртекнең,
Алтын бөртек әти-әнигә.
«Син олы кыз», – диде икесе дә,
Карамады буем нәнигә.

Апа идем эне-сеңелләргә,
Әти-әниемә – ышаныч.
Авыр чакта туган кулын сузу –
Минем өчен иде бу бурыч.

Апа булып, аклап яшим һәр көн,
Өзелмәсен өмет-ышаныч.
Биш бармакның бишесе дә әрни,
Кайсын киссәләр дә кызганыч.

Һаман шулай, иң олысы булып,
Алтын бөртек булып яшимен.
Анадан күп бала тугач, чыннан,
Олысына авыр, яшермим.

## *Кагылмагыз яраларга!*

Айрылулар авыр икән,
Сагынулар дару микән?
Сыңар канат калды канап...
Кайтмас җиргә китте иркәм.

Кагылмагыз яраларга,
Тырышмагыз дәваларга.
Сөйгәнемнең карашыннан
Башка дәва юк аларга.

Ялгышларны кабатладым,
Киселделәр канатларым.
Кайтмас җиргә китте ярым...
Мин башканы яратмамын.

Кагылмагыз яраларга,
Өмет итеп дәваларга.
Сөйгәнемнең назларыннан
Көчле дәва юк аларга.

Белмәгәнгә кадерләрен,
Кисә йөрәк бәгырьләрен.
Бер киткәннәр кайтмыйлар шул...
Кочып елыйм каберләрен.

Кагылмагыз яраларга,
Бер дәва да юк аларга.
Уртак юллар аерылды...
Үлем керде араларга.

## Яфрак яңгырлары

Җиргә ява яфрак яңгырлары,
Сары келәм булып түшәлә.
Кыр казлары китәр юлга чыккан,
Каңгылдашып: «Хуш...» – дип үтәләр.

Җиргә ява яфрак яңгырлары,
Салмак кына очып төшәләр.
Хушлашалар җәйнең яме белән,
Тавыш-тынсыз гына китәләр.

Җиргә ява яфрак яңгырлары,
Гомер агачыннан коелып.
Җәйләр белән көзләр алышканда,
Сагышлардан булмый тыелып.

* * *

Җанымның сафлыгын алыштырмыйм
Берни белән дә.
Хисләрем яктысын караллтмыйм
Берни белән дә.
Җанымны тапларга, хисемне вакларга
Тырышмагыз,
Мине белгәннәр!

## Кыр казлары хушлашуы

Тезелешеп кыр казлары китә –
Һаваларда аваз.
Йорт казлары кала каңгылдашып –
Көнләшүле караш.

Үлән кипкән,
Китәр вакыт җиткән, –
Кагына пар канат.
Оя-оя кыр казлары китә:
«Кайтырбыз, – дип, – кабат».

...Гомер буе шулай –
Канатсызлар
Канатлыдан көнле.
Елый-елый читкә китеп барган
Җан хәлләрен белми...

## Сорау

Гомер буе бер сорауга
Җаннан җавап эзлим мин:
Яшерен, бикле күңелләрне
Ничек итеп ачарга?
Аңлар өчен бөтен серен
Нинди ачкыч табарга?
...Мәхәббәттән гайре йөрәк
Ачкычларын күрмим мин.

## Таныш түгел җирдә танышлар

Таныш түгел авыл,
Таныш түгел сукмак.
Шул ук тормыш кайный монда да.
Тирә-якны күзлим,
Таныш йөзләр эзлим –
Кеше үзгәрми ул кайда да.

Сызып карлар эри.
Җилләр уйнап йөри –
Тәрәз кәрнизендә күгәрчен.
Кышны озатамы,
Язны каршылыймы?
Канат җилпеп куя, күрәмсең?

Таныш түгел күңел,
Таныш түгел йөрәк,
Төпсез дәрьямы син җиһанда?
Аккан сулармы син,
Искән җилләрме син,
Ялгыз юлчымы син буранда?

Таныш түгел кеше –
Укылмаган китап.
Аңлар өчен серле – хакыйкать.
Язгы яңгыр ява,
Соңгы карны юа –
Күз төсендә язгы табигать.

Бүген бар да яңа,
Бүген бар да серле –
Сукмак саен көтә табышлар.
Ә иртәгә монда
Табылырлар миңа
Таныш түгел җирдә танышлар.

# Соңгы дәрес

Ак алъяпкыч иңнәремдә,
Кулда – аттестат.
Соңгы кыңгырау чылтырый –
Саубуллашыр чак.

Дәресемнең соңгы көне,
Моңсу мизгелләр.
Өстәлемдә энҗе чәчәк,
Ап-ак сиреннәр.

Саубуллашу дәресе бу,
Хәтер дәресе.
Соңгы кыңгырау чылтырый –
Уйда һәр кеше.

Көмеш кыңгырау тавышы
Чыкмас хәтердән.
Теләкләрнең иң изгесе
Монда әйтелгән.

Олы юлга хәер-дога
Соңгы кыңгырау.
Гомер буе онытылмас
Шушы яңгырау.

## Вокзал

Дөньясының йөген салдыңмы син
Иңнәреңә, вокзал, гомергә.
Юл сабучы булдың гомер бакый,
Сыеныр почмак кайтыр-китергә.

Адәмнәрнең йөген салдыңмы син,
Борчуларын җанга алдыңмы?
Үткән-сүткәннәргә җылы биреп,
Туктар почмак булып калдыңмы?

Нинди генә юллар үтми кеше,
Һәм һәрберсе синдә туктала.
Юллар кисешкән урын син, вокзал,
Бөтен кеше синнән юл ала.

Очраштырыр урын бик күпләрне,
Аерып киткән юл да синеке.
Мин дә бүген синдә поезд көтәм,
Димәк, бүген мин дә синеке.
Димәк, син дә бүген минеке.

* * *

Мин юлларга чыгам сине уйлап,
Очраштырмас микән юлларым.
Поезд тәгәрмәче моңнарына
Кушылып туа яңа җырларым.

Мин юлларга чыгам бәхет эзләп,
Бер табылыр төсле эзләгәч.
Борма юллар алып китте мине,
Көтүләргә бүтән түзмәгәч.

# Хәерле юл сезгә!

*Чыгарылыш сыйныфларга*

Яңа гасыр атлый җиһан буйлап,
Ак күгәрчен уйный күкләрдә.
Өмет, шатлык, бәхет вәгъдә итә,
Уңышлы юл тели күпләргә.

Өченче ел шаулый яңа гасыр,
Туып килә үзгә бер дәвер.
Ак күгәрчен очкан якты еллар
Олы дастаннарга әйләнер.

Сез киләсез гасыр түрләреннән,
Беренчеләр булып юл салып.
Сез – тарихка нигез салучылар,
Бүгенгедән янар көч алып.

Зур тарихка үтәр юллар аша
Озата барыр мәктәп еллары.
Егермедән егерме беренчегә –
Сәлам кыңгыраулар чыңлавы.

Очар канат биргән туган мәктәп,
Ышанычлы, ныклы канатлар.
Гасыр буйлап килер көмеш чыңнар,
«Мәктәбем» дип йөрәк кабатлар.

Чынга ашсын бөтен хыялыгыз,
Сынатмагыз юллар үткәндә.
Хәерле юл сезгә, изге теләк
Олы юлга чыгып киткәндә!

# Чыршы зары

Кинәт кенә шаулап-гөрләп үскән
Агачларга пычкы салдылар.
Тупыллардан ап-ак мамык очты,
Ак каеннар елап аудылар.

Авыл уртасында киселмичә
Ялгыз башы калган бер чыршы:
– Әйтегезче, тупыл-каеннарны
Кисәргә, – дип сорый, – кем кушты?

Тупыл мамыклары күзгә кереп
Кәефен кырган «олы хуҗа»ның.
...Бу әмерне язган куллар корыр,
Күтәралмас каен елавын.

Кеше каргышлары төшмәсә дә,
Агач каргышлары бер төшәр.
Дөнья куласасы хәрәкәттә:
«Әйләнә дә баса бер кучәр».

Әйләнә дә баса кабат-кабат,
Алмашына тора хакимнәр.
Адәм түгел, агач куркып тора:
Тагын чыгар нинди хөкемнәр?

Гади халык күндәм, ялагай ул,
Кол фигыле яши канында.
Зур түрәләр кушса, сорап тормый,
Кыеп куя адәм җанын да.

Инсаннарның вәхшилеген күреп,
Ярдәм сорыйм синнән, Тәңрем!
Кодрәтеңнән килә синең генә,
Хөкем итү хаким әмерен.

Шаулап торган зифа каеннар юк,
Ак мамыклы яшел тупыллар.
...Авыл уртасында чыршы елый,
Белмим, тагын күпме сулкылдар.

Агач тамырларын төпләделәр,
Утырттылар яңа чыршылар.
Әбелхәят суы качкан иде –
Яфрак яралмыйча кордылар.

И хакимнәр, ник кул күтәрдегез?
Гел бер сорау бирә бу йөрәк.
Тупыл башка мамык очыралмас, –
Бер гаепсез иде табигать.

## Туган як бар

– Бу кадәр йөрәккә бик якын
Тагын ни бар? – дисәм:
Үзенә гел тартып торучы
Туган як бар икән.
– Бу җирдә әни күк кадерле
Тагын кем бар? – дисәм:
Йөрәкнең тагын бер газизе –
Ул сөйгән яр икән.
Яшьлеккә чакырып торучы
Мәктәбем бар икән.
...Барсын да бертигез сагынып
Җирсүләр хак икән.

# Барысын да кичерәбез

Төрле вакыт була,
Аяк чала кемдер,
абынабыз.
Кайвакытта,
очкын кебек,
бер сүздән дә
кабынабыз.

Тормыш юлы тайгак...
Ләкин
һаман югарыга,
үргә, дибез.
Егылсак та, янә торып,
Алга таба үрмәлибез.

Кемдер сөйми безне...
Ярдан аска төртә.
Берәү килеп хәлең белә,
Авыр чакта ярдәм итә.

Начарлыклар онытыла,
Үпкәләрне кичерәбез.
Игелекләр мәңге бетми...
Шулай булмый –
Кешеләр без.
Хыянәттән кала җирдә
Барысын да кичерәбез.

# Туган көнеңә

*Ф-гә*

Февраль иртәләре аяз бүген.
Син туасын, бәлки, сизгәндер.
Ак карларга бары синең өчен
Энҗе бөртекләрен тезгәндер.

Чал табигать шундый садә бүген,
Көнләшмичә карау мөмкин түгел.
Аяз күктә якты кояш көлә,
Әйтерсең лә синең керсез күңел.

Асыл затның сыйфатлары асыл,
Изгелектер кылган гамәле.
Ак бәхетләр алып килсен сиңа,
Канат бирсен дуслар сәламе.

## Яңа елның туллган ае

Бөтен дөнья акка төренгән дә
Яңа елны көтә тын калып.
Кышкы күктә түгәрәк ай йөзә,
Күл сулары сыман чайкалып.

Ай күптәннән җиргә карап тора,
Мөлдерәмә итеп күзләрен.
Калдырасы килми үткәннәрдә
Иске елның алтын көннәрен.

Үзе белән алыр иде барсын:
Нурлы язын, ак, тын кышларын,
Шау чәчәкле җәен, болыннарын,
Урман-күлләр, сайрар кошларын.

Калдырмыйча алып килер иде
Бар ямьнәрен яңа елларга.
Йөрәгенә салып тик яхшысын
Ай нурында туган юллардан.

# Чулманда таң туа

(Җыр)

Ак томаннарны аралап,
Чулмансуда таң туа.
Җырчы акчарлаклар уйнап,
Дулкын өстенә куна.

Кушымта:

Чулманым син, Чулманым –
Таң йолдызым – Чулпаным!

Сибелә кояш нурлары,
Туган якта таң туа.
Дулкын-дулкын агымсулар
Чулман ярларын юа.

Кушымта.

Тибрәтеп күңел кылларын
Кояш белән таң туа.
Уйлар өермәсе сыман,
Дулкынны дулкын куа.

Кушымта.

Уйларым сиңа тоташа,
Йөрәккә шатлык тула.
Тарала бөтен сагышлар –
Чулмансуда таң туа.

Кушымта.

# Һаман бер сорау

Пароходлар елаганын
Күргәнең бармы, сеңел?

*Кадыйр Сибгатуллин*

Күңелдә һаман бер сорау:
– Пароходлар елаганын
Күргәнең бармы, сеңел?
Пароходларга пышылдыйм:
– Елауның нәрсә икәнен
Югалткач белде күңел...

Йөрәктә һаман бер сорау:
– Пароходлар елаганын
Күргәнең бармы, сеңел?
Бөтен җиһанга кычкырам:
– Ак пароходка утырып
Кайтыр, дип көтә күңел.

Сагынып көтә ярларың,
Боекканнар талларың...
Кайтаваз җавап кайтара:
– Туган җирдә калдым мәңге,
Ташлап китә алмадым...

## Сагынам

Туган якның сагынам тугайларын,
Болыннарын, челтер суларын.
Туган ягым – саф сөюем минем,
Туган ягым – яшьлек җырларым.

Туган яктан назлы җил искәндә,
Сыйпасын дип, битем куямын.
Еллар ерагайта, ә йөрәкнең
Җиргә якынлыгын тоямын.

## Туганнар

Башкалада, ташкалада
Яшисез лә, туганнарым.
Беләсезме, илдә сезне
Көн дә көтеп торганнарын?!

Әткәй-әнкәй нигезенең
Миләшләре көтә сезне.
Язлар саен чәчәк атып,
Яныл-пешеп бетә көзне.

Язлар саен яфрак ярып,
Алмагачлар көтеп тора.
Көтә-көтә саргаешып,
Алмагачлар яфрак коя.

Баланнары туй күлмәге
Киеп көтә, кайтырсыз дип.
Туганнарым, көттермәгез,
Бер күрешү – бер гомер бит.

* * *

Бүген әле сине төштә күрдем,
Сагынганмын икән, сагынган.
Араларда барыбер тирән упкын,
Йөрәгемә куштым: сабырлан!

Ә син һаман шундый, үзгәрмәгән,
Элеккечә зәңгәр күзләрең.
Әле дә шулай якын икән миңа
«Җимешем син» дигән сүзләрең.

Төшләремдә син гел иптәш миңа,
Өннәремдә ялгыз язмышым.
Нигә инде төшләргә керәсең,
Яшьлектәге татлы ялгышым?

## Кирәмәт

Кирәмәт күл суларында
Йөзәдер алтын балык.
Авылым Тегермәнлектә
Яшидер ялкын халык.

Кирәмәт күл суларында
Йөзәмен колач салып.
Тегермәнлек – туган җирем,
Яшим синнән көч алып.

Кирәмәт күл тирән сулы, –
Шифадыр җаннарыма.
Тегермәнлек, кайтам сагынып,
Булсам да кайда гына.

# Хәтерлиләр

*Нәсимә апага*

Монда һәрни сине белә
Һәм хәтерли. Онытмаган.
Язгы күкрәү төсе итеп,
Яңгыр коя болытлардан.

Үлән типкән, чәчәк аткан,
Җилләр уйный басу якта.
Капкаларны ачып керә,
Сине көтә, сагынып кайткан.

Алмагачлар алма бирә,
Карлыганнар каралганнар.
Кураҗиләк җимешләре
Чәчәк саен яралганнар.

Монда һәрни сине көтә,
Кайтырсың бер, түзмәссең, дип.
Җилләр төсле капка ачып
Кайтып керче, сагындык бик.

# Урман

Серле урман – җырлы урман,
Кәккүкләрең моңланадыр.
Тәкәрлекләр тавыш бирә,
Үләннәрдә чык янадыр.

Бөрлегәннәр өлгергәннәр,
Каенҗиләк – тәлгәш-тәлгәш.
Шау чәчәккә күмелгәннәр
Кураларың әлегә яшь.

Серле урман – якты сукмак,
Сандугачлар тынмый бер дә.
Кошлар иле кайнап тора,
Талларың да җырлый синдә.

## Җир - ул бер генә

Җир-ананың күкрәгеннән чыккан
Зәңгәр чишмәләрнең, күлләрнең
Тын сулышын буа химикатлар,
Чәчәкләре сула гөлләрнең.

Җир-ананың күкрәк сулышларын
Ашламалар буа сиздерми.
Сайрар кошлар тына әрәмәдә,
Сулыкларда балык көн күрми.

Җир ул – берәү генә безнең өчен,
Эчәр су да, сулар һава да.
Зәңгәр күлләр, яшел урманнары
Сихәт бирә торган дәва да.

# Туган җир генә

Кайтыр юлга чыкты поезд,
Тагын ашыга.
Йөрәккәем җырлый кушлып,
Поезд таушына.

Кайтыр юлга чыктым ярсып,
Сагыну – чиксезлек.
Туганнар белән бергә дә
Авыр җирсезлек.

Кайтыр юлга бүген йөрәк
Ярсый, ашкына.
Кайда да туган җир кирәк
Адәм халкына.

Башкаладан кайтып киләм
Җирсеп җиремә.
Дәва булыр, сихәт бирер
Туган җир генә.

Бар да әзер, рәхәт, ләкин
Авыл юк монда.
Кайда булсам да сагынам
Шуңа мин юлда.

Алма бакчаларым көтә
Чәчәк атасы.
Шуңа күрә киткән саен
Килә кайтасы.

# Игенче хезмәте

Табигать язларда яшәрде,
Басулар киң сулыш сулады.
Кояшның бу җылы карашын
Игенче муллыкка юрады.

Сукасы, тырмасы гел әзер,
Җир сөрде кызганмый хезмәтен.
Җан өрде ул алтын бөртеккә
Һәм бирде җанының куәтен.

Күз текәп кырларга өзлексез
Һәр бөртек тибешен күзәтте.
Басуда уҗымнар гөрләде,
Бодайлар шаулатты хезмәте.

Булса да кипшергән бер бөртек,
Туфракка төшкәндә өмете.
Илаһи көч бирде игенче,
Хезмәте туфракны гөл итте.

# *Мең яшәче, әни!*

*Әнкәйгә*

Синең кебек сабыр затлар юктыр
Җирдә генә түгел, җиһанда.
Кояш җылы, көн яктырак сыман,
Яныбызда, әни, син барда.

Гел янәшә булсаң иде, әни,
Синең кайгыртуың бик кирәк.
Җирдә генә түгел, җиһанында
Синдәй асыл затлар бик сирәк.

Еллар арты еллар узып бара,
Безнең өчен яшәп җан атып.
Җирдә генә түгел, җиһанында
Синең төсле булмый яратып.

Баштан сыйпасаң да рәхәт, әни,
Иң җылысы синең кулларың.
Мең яшәче, әни, кайгы-хәсрәт
Күрсәтмәсен килер елларың!

# Еллар сынаса да...

Кырыс еллар кырык сынаса да,
Каршылыклар юлда тезелеп.
Сынмагансың, әти, сынмагансың –
Офтансаң да үзәк өзелеп.

Узган гомер – авыр хезмәт юлы,
Борчулары килгән ишелеп.
Яманлыктан безне яклагансың,
Кылган гамәлләрең – игелек.

Батырлыкка өлге – яшәү юлың,
Кальбең сафлыклары – үрнәктер.
Сыек буыннарны яратмыйсың,
Синең йөрәк – олпат йөрәктер.

Кан тамырларыңда гаярьлек бар,
Картаюга һич баш бирмисең.
Әни төсле безне кайгыртып гел,
Бәхет сорап, теләк телисең.

# Әни

Егылганда, аяк тайган чакта,
Әни коткара гел барсыннан.
Ак яулыгын болгап әни озата,
Әни чыга әүвәл каршыга.

Һәр атнаны көтеп без кайтканны,
Самовары төшми өстәлдән.
Сабыр гына көтә, күзләрендә –
Яшь пәрдәсе, – күңел нечкәргән.

Бер карашка тыныч кебек үзе,
Ә җанында тоташ ялкын бит.
Бишебез дә йөрәк парәседәй,
Бишебез дә бердәй якын бит.

Җыерчыклы, эшчән кулларының
Назлары юк башка һичкемдә.
Буй җитсәк тә без әнигә сабый,
Без һаман да әни иркендә.

# Янәшәмдә Тукай

Шигырь көне бүген, шагыйрь көне –
Туган көне бүген Тукайның.
Нурлар чәчеп тора һәр иртәсе
Хөр Тукайлы иткән бу айның.

Тукай урамыннан атлап киләм,
Эзләренә басып баруым.
Очкын тулы күзләреннән күрәм
Халкы өчен ничек януын.

Мәрмәрләргә сеңеп калган сыны
Ирек мәйданында – мөнбәрдә.
Телдән телгә күчеп «Туган тел»е
Рухи балкыш өсти меңнәргә.

Җырлы-моңлы улы ул татарның,
Гади улы, түгел фәрештә.
Йөрәгендә һаман гавам уе,
Чал Тукайның җаны гарештә.

Янәшәмдә сизәм мин Тукайны,
Тоям гүя җылы карашын.
Дөрләп яна-яна иҗатының
Яңа гасырларга барасын.

Гөлләр куям Тукай һәйкәленә,
Шигырьләре белән серләшәм.
Шигырь каһарманы, үлмәс җырлы
Тукайны мин тоям янәшә.

# Болар – сезнең, минем газизләрем

*Татарстанның халык шагыйре,*
*якташым Равил Фәйзуллинның*
*юбилее уңаеннан*

Балтач урманнарын бер иттереп
Чыгып киттең олы дөньяга.
Татарның зур, шау дулкыны булып,
Чулманыңнан күчтең дәрьяга.

Горурланып туган яклар белән
Сәяхәттә йөрдең чит илдә.
«Күмәч пешерүче җыры» аша
Ихлас кердең безнең күңелгә.

Иделләрдә йөзгән паромнарың,
«Тәкыялы урман кызлары».
Сабый чакта якын дәү әнинең
«Аяк бөкләп торткан йомгагы» –

Болар – сезнең, минем газизләрем.
Түбән болыннарның җәйләве,
Абагалы яшьлек урманнары,
Сапа чишмәләре, «Зәйнәб»е –

Болар – сезнең, минем якыннарым,
Тормыш фарватеры көй-җырның.
Сабантуйлы таулар, Шарлы суы
Онытмыйча көтә үз улын.

Бик күрәсең килгәнлекне сизеп,
Урман кызы чыкса ни булыр?
«Ландыш тәкыялы» яшьлегеңнән
...Күңелеңдә яңа җыр туар.

Ул җыр булыр тагын безнең хакта,
Бик якынсың, якын туган якка.
Алтмышыңнан алтыңа күч, шагыйрь,
Әйләнеп кайт сабый, садә чакка!
Олуг бәйрәм бүген сезнең хакка.

## И хатын-кыз

*Фәрвәзгә*

Якты яз елмая кояш булып,
Гөрләвекләр ага юллар тулып.
Җырын бүләк итә сандугачлар,
Бөреләре тулган талга кунып.

Тышта яз елмая синең төсле,
Язын кояшның да нуры көчле.
И хатын-кыз, тиңең юктыр башка,
Күңелкәең яздай нечкә хисле.

Карашыңнан җылы нур бөркелә,
Кояш төсле яна, сөя белә.
И хатын-кыз, синең төсле иркә,
Якты язлар килә көлә-көлә.

Илаһилык телим, бәхет кенә, –
Язлар белән җанга шатлык иңә.
И хатын-кыз, артсын сөенечең,
Яшә җирдә уйнап-көлеп кенә!

# Имәннәр баш ия

*Татарстанның атказанган урманчысы*
*Харис Мусинга*

Табигатьтә бөтен нәрсә тәртип белән:
Имәннәр бар – урманнарның зур җегәре.
Нечкә билле каеннары – затлы бизәк,
Ә күлләре – табигатьнең көзгеләре.

Табигатьтә бөтен нәрсә сокланырлык:
Мәңге яшел наратлары күккә карый.
Нинди генә аһәңнәр юк урманнарда,
Күкеләре акрын гына гомер саный.

Җирдә үткән һәр ел саен аваз сала:
Бер-ике... ун-егерме... илле җиткән.
...Малай булып кергән идең урманнарга,
Имәннәргә тиң булырлык гомер үткән.

Хуҗа булып атлыйсың син, колач җәеп,
Яшәү биргән урманнарың сөя-сөя.
Җаныңдагы көч-кодрәткә соклanудан
Йөзьяшәрлек имәннәрең башын ия.

# Безнең егет

*Аксубай районы хакимият башлыгы,*
*якташым Илһам Вәлиевкә*

Аксубайлар уңган халык,
Бик бай диләр ул якны.
Кара алтын чыгаралар,
Алар мактауга хаклы.

Хуҗалары уңган егет,
Аңлый халык теләген.
Алдан күреп яши белә
Халыкка ни кирәген.

Аксубайда эшләр уңай,
Бердәмлектә яшиләр.
Мул уңышлар үстерәләр,
Сүздән борчак чәчмиләр.

Хуҗалары – безнең егет,
Эшкә батыр, чын лачын.
Җиң сызганып эшләп яши
Кызганмый көч-колачын.

# Вэзыйхна

*(«Тормыш арбасы» дигән китабы чыккач)*

Җирдә кеше туган вакыт,
«Җилләр ни җырлый» икән?
Ир уртасы булып җиткән
Ирләр ни уйлый икән?

Аларның да «онытылып»
Киләдер ял аласы.
Ләкин булмый, талкый дөнья –
Өстә «тормыш арбасы».

Заман аты сыман тарта
Тормыш йөген җигелеп.
Китаплары чыга тора,
Кыла тора игелек.

Бу җиһанга әле һаман
Гашыйк булып тора ул.
Чын шагыйрьләр туганда ук
Шагыйрь булып туа ул.

# *Гаффарлар*

*Әхәткә*

Әшнәклләрдән Казанга килеп,
Бистәләрнең данын яклadың.
Олуг юбилееең белән котлап сине
Сәлам юллый туган якларың.

Рәкыйп, Әхәт, Ринат Гаффарлар –
Өчәү бергә бигрәк көчле сез.
Әдәбият-сәнгать дөньясында
Алып батыр төсле эшлисез.

Эшең белән раслап яшисең син,
Бистәләрнең аклап өметен.
Олы бәйрәмнәрең котлы булсын,
Әшнәкләрнең олпат егете!

# *Йолдыз төсле*

*Галия апага*

Йолдыз булып кабындың син күктә,
Төнем шыксыз кара чагында.
Якты нурың белән юл күрсәтеп
Алып чыктың тормыш таңына.

«Җиңел килгән бәхет бәхетмени?
Эзләп тапкан бәхет кадерле...»
Юатты бит җырың һәм терелтте
Телгәләнеп беткән бәгырьне.

Йолдыз булып кердең күңелемә,
Таңнарда да сүнми яктысы.
Саф күңелнең изгелеге булып
Туды җанда бәхет чаткысы.

# Алтын туйда

Нәкъ 50 ел элек моннан
Саф мәхәббәт табыштырган.
Сөю-сәгадәт утлары
Гомерлеккә кавыштырган.

Чылтыр-чылтыр ага гомер,
Әйтерсең лә көмеш чишмә.
Сезнең гомер җырын җырлап,
Сезнең йөрәк серен чишә.

Бәхетләрен шулай тапкан
Сезнең кебек күпме парлар.
Сүрелмиләр кайнар хисләр –
Сез 50 ел гашыйк ярлар.

Нәкъ 50 ел моннан элек
Чәчкә аткан сөюегез.
Алтын туйда бәхет теләп
Яратыгыз, сөелегез!

# Ак яулыклы күрше әби

*Хәтимә Гыйлаҗевага*

Язы – җәйгә, җәе көзгә алмашына,
Көзләрдән соң ап-ак булып кышлар килә.
Яшәүләрнең мәгънәсенә гамьнәр өстәп,
Бар җиһанга җем-җем иткән нурлар иңә.

И әйләнә бертуктаусыз, и әйләнә,
Хәрәкәттә тора дөнья тәгәрмәче.
Маңгайлардан сыйпап узган заман җиле
Ак кыраудай агарта да куя чәчне.

Ундүрт яшьтән җиккән дөнья арбасына,
Авырлыклар йөге белән төшкән иңгә.
Кулыңдагы сөялләрең, маңгай сырың –
Хезмәт иткән билгеләрең туган илгә.

Буй җиткергән балаларың, оныкларың –
Барысы да – синең уңыш, синең шатлык.
Йөзгә кадәр яшә әле якты көндә!
Тик килмәсен ялгыз булып сиңа картлык.

Чын күңелдән, саф күңелдән ил-көннәргә
Намаздан соң һәр кичендә теләк тели.
Мең рәхмәтләр яусын сиңа доганң өчен,
Ак яулыклы, ак күңелле күрше әби.

# Урман кызы

Апам Миңлебикәгә

Тормыш сыйпап иркәләмәде гел,
Елмайдык без, елар булсак та.
Талчыбыктай хатын-кызга түгел,
Имәннәргә авыр бер чакта.

Имәннәрнең чыдый алмый, түзми
Бөгелгәнен күрдек, сынганын.
Ә син бирешмәдең, урман кызы,
Кайгыларны җиңдең, сынмадың.

Якты язда умырзая җыеп,
Җәйләрендә пешкән җиләгең.
Күки урманының нигъмәтеннән
Тулып торды кәрҗин-чиләгең.

Бернәрсә дә үзгәрмәгән төсле,
Умырзая назы җилләрдә.
Йөзләреңдә уйный кояш нуры,
Таллар нечкәлеге билләрдә.

Кылдай нечкә синең күңелкәең,
Ак каеннар төсле саф, садә.
Пар канатларыңа ныклык телим,
Урман кызы – дустым Шаһзадә!

# Солтан булды Солтан егете

*Татарстанннның халык артисты*
*Равил Шәрәфиевкә*

Һәр халыкның була үз батыры,
Үз Тукае була, Җәлиле.
Һәр авылның була үз Хуҗасы,
Насретдине була – Равиле.

Иҗатында дөрләп яна-яна,
Солтан булды Солтан егете.
Халык мәхәббәтен яулады ул,
Һәрбер татар аны үз итте.

«Хуҗа Насретдин»не уйнаганда
Гөрләп кенә торды сәхнәләр.
«Әҗәл» булып кинәт сискәндерде,
«Хаҗи әфәнде»сен өйләндерде.
...Пәрдә арты менде пәрдәләр.

Ничә кайтса да ул туган якка,
Бәйрәм бүләк итте авылга.
Көлдерде дә безне яшь аралаш,
Кинәт елатты да җирсетеп...
Рәхмәт яусын артист Равилгә!

# Йөрәгендә гавам уе

*Русиянең атказанган*
*авыл хуҗалыгы хезмәткәре*
*Равил Хәйруллинга*

Гавам йөген тарта асыл затлар,
Олпатлыклар чын ирләргә хас.
Йөрәгенә халкы гамен салып,
Зур хезмәттә үткән гомер хак!

Йөрәгендә – ил турында уйлар,
Акыл эзе – маңгай сырында.
Ал таңнары басуларда туа,
Йөрәк моңы – тургай җырында.

Күңел кылларында иген шавы,
Гөрләп үскән яшел уҗымнар.
Хезмәт мәдхиясе – үзе һәйкәл,
Таң калырлык туар токымнар.

Гавам уе, гавам гаме йөрткән
Олпатлыклар чын ирләргә хас.
Маңгай тире белән эшләп тапкан,
Чын хезмәттә үткән гомер хак!

## Туй теләкләре

Пар канатлар талмый, диләр,
Канатыгыз пар булсын!
Икегез дә сөйгәненә
Бердәнбер тиң яр булсын!

Йолдыз кебек якты янып,
Үтсен яшьлек хозурланып!
Хезмәттә дә, гаиләдә дә
Кирәк кеше булыгыз!

Ил чакырса – Ватан өчен
Терәк булып торыгыз!
Картаймагыз, авырмагыз
Һәм яшәүдән арымагыз!

## Мактану

Чыпчык тезеннән булса да
Эшләгән эше,
Филне кумәрлек сүз сөйли
Мактанчык кеше.

## Компьютер

Электрон укытучы
Өстәл түрендә.
Җанда бушлык, нидер җитми
Безнең күңелгә.

Электрон укытучы –
Җансыз машина.
Җитәр, ахры, изге хисләр
Шәфкать башына.

## Куәт

Хакимнәрдә хикмәт бардыр,
Фикерләүне аңа калдыр!
Ни әйтсә дә хаклы булыр,
Хакимнәрдә куәт бардыр.

## Теләк

Әкерен генә кешеләрне күзлим –
Күңелләргә телим керергә.
Күңел – көзге, әмма мөмкин түгел
Җанның чагылышын күрергә.

# Ак Сарайда серләр бар

(Поэма)

Хан ярлыгы кемдә?
Хан ярлыгы Ак Сарайда, саклагыз!

*Җиденче буын бабам Юлдаш васыяте*

1

Ак Сарайның тирән серләре бар,
Гасырларга китә тамырлар.
Нигез ташларына баш иярләр
Горурланып, туар токымнар.

Ничә гасыр йөри телдән телгә,
Васыять йөри күчеп нәселгә.
«Хан ярлыгы Ак Сарайда», – диеп,
Буын саен васыять әйтелә.

Җиде буын кендек җеп тоташкан
Юлдаш бабам нәсел токасы.
«Хан ярлыгын җуймый саклагыз!» – дип
Аваз сала дәвер кыйтгасы.

«Ярлык яшерелгән Ак Сарайга,
Хан ярлыгын шуннан эзләгез!»
Юлдаш, Хисмәт бабам кайтавазы:
«Нәсел затлылыгын өзмәгез!!!»

Ничә гасыр телдән телгә йөри
Әверелеп олы әмергә.
Улдан улга, васыятьнамә булып,
Дәверләрдән күчә дәвергә.

Зур тарихлы таш Сарайда күзләр,
Җиде катлы дивар нигезе.
Хәтта ташлар телгә килерләр дә
Әйтелер күк васыять сүзе.

Болгар диварларын хәтерләткән
Ак Сарайның сере нидә соң?
Кемнәр бүген мең сер яшерелгән
Гасырларның серен сөйләр соң?

2

Ерак тарих – Бөек ханнар юлы
Таш диварга килеп тоташа.
Алтын Урда хаким булган чорга
Ак Сарайдан күчәм уй аша.

Гасырларны кичеп уй йөгерә
Алтын Урда – Чыңгыз чорына.
Хан ярлыгы хатирәсе яши,
Кушылып яши «Чулпы җыры»ма.

Берсе анам, берсе атам каны –
Нигез-тамырларым билгесе.
Бабаларым Ваһаб, Сөнгать, Нәҗми –
Намус өлгесенең көзгесе.

Ак Сарайга яшерелгән ярлык,
Кайсы ханнан килгән әмер соң?
Чыңгыз, Батый, Үзбәк Бирдебәкме
Ярлык язылганда әмир соң?

Олыс җитәкчесе иткәнме ул
Җиде буын бабам Юлдашны?
Илче иткәнме ул чит җирләргә,
Әмер җиткерүче юлбашмы?

Бәлки, җир биләүче билгеседер
Ал тамгалы ярлык нәселгә.
Хан ярлыгын җандай саклаганга
Сарай диварына яшергән.

Һәм сакларга кушкан боерыкны,
Нәсел горурлыгы – ярлыкта.
Бирәү аны ханнар буыны, ди,
Бик күп фаллар йөри халыкта.

Хан даирәсеннән чыккан углан, имеш,
Зур дипломат, диләр кемнәрдер.
Нәсел агачымның тамыры учар,
Тармаклары йөзләр, меңнәрдер.

3

Берсе әйтә:
«Ханның дәвамчысы Юлдаш,
Булсын сиңа чук-чук сәламнәр.
Ал каймасы – шуның шәһадәте,
Чыңгыз улын күрегез, адәмнәр!»

Ефәк чуклар белән төргән ярлык –
Хан мөһерен суккан чынлыкка.
Шөһрәтеңә шаһит гомер бакый,
Таш Ак Сарай тора тынлыкта.

Ышанычын шулай белдергән хан,
Ярлык күчкән улга, оныкка.
Үткәннәрдән аһәң яңгырашы:
«Җиде буыныңны онытма!»

Бирдебәккә ясак җыйган, диләр,
Чулман буйларыннан Юлдашны.
Җанибәк углының дусты булган,
Киңәшчесе, имеш, юлдашы.

Ал тамгалы ярлык шөһрәт биргән,
Исем биргән, дан һәм дәрәҗә.
Нәселемдә Укмасыйлар каны,
Данлы, шанлы безнең шәҗәрә.

Баксаң, әле минем тамырларда
Чыңгыз ханнар каны агадыр.
Жучи нәселе угыллары бар да
Кардәш-ыру, ерак бабамдыр.

Ничә гасыр йөри бу васыять
Юлдаш карттан күчеп нәселгә.
«Хан ярлыгын югалтмагыз!» – диеп,
Ул теләгән күпне әйтергә:

Гаярь, батыр, ир йөрәкле булу –
Гөлстанның гөле итәдер.
Намусың саф, ихтыярлы булсаң,
Гомер һәрчак ямьле үтәдер.

4

Ул сакларга кушып хан ярлыгын
Үлемсезлек тели җанына.
Ак Сарайда калган хан ярлыгы
Ихлас шаһит аның данына.

Ул сакларга кушкан милләтен дә,
Югалтмаска кушкан телен дә.
Хан ярлыгы әманәте булган
Бердәм саклар өчен илен дә.

Әмма җуйдык, ярлык эзсез китте,
Васыятьне үти алмадык.
Буын белән буын ялганмады –
Зур ялгышны соңлап аңладык.

Үзем бүген бабам урынына
Сүз әйтергә җөрьәт итәмен:
Хан ярлыгын аклар Ир туганны,
Хакын хаклар көнне көтәмен.

Болгар диварларын хәтерләткән
Таш Сарайның сере нидә соң?
Мең сер яшерелгән кыйтгаларда,
Хан ярлыгы хәзер кемдә соң?

5

## Дәүләт сәгате

Дәүләт сәгате күзгә күренми.
Ул муллык, бәхет, дәүләт теләп тора.

*Борынгы риваятьтән*

Ак Сарайда Дәүләт сәгате бар –
Гасыр чаптарында узганы.
Риваятьләр сөйли кайтавазлар,
Күтәрелә дәвер тузаны.

Ялгыз калып кына тыңлыйлар, ди,
Бу сәгатьнең серле тавышын.
Санап тора дөнья әйләнешен,
Айлар, еллар, гомер агышын.

Санап тора һәр минутын, мәлен,
Теләп тора тәүфыйк, сәгадәт.
Көнең бәрәкәтле, тормышың бай,
Нигезеңдә булса бу сәгать.

Бала чакның серле мизгеленә
Дәшеп тора сәгать чылдыры.
Үткәннәргә әйдәп алып кайта
Дәүләт сәгатенең чылбыры.

Алып кайта яшьлек хыялларга,
Чынбарлыклар белән тоташа.
Күпме дастаннарда дан җырланган:
Бу сәгатьтә кодрәт тамаша.

Алтыннанмы икән, көмештәнме,
Бәллүр микән әллә телләре?
Хыялымда күрәм һәм үрелеп
Тартып куям сәгать герләрен.

Бала чакның серле хатирәсе:
Келт-келт сәгать йөри Сарайда.
...Мин серемне чишәм якын күргән
Сабый дустым – күрше малайга.

6

Алып кереп китәм Ак Сарайга,
Ярсый йөрәк, хисләр талпына.
Ташлар арасыннан күзәтүче,
Карап торган күзләр бар сыман.

Дәү әнием хикәятен сөйлим:
«Дәүләт сәгате бар нигездә.
Бик бәхетле йортта гына була,
Озак еллар йөри ул бездә».

И беркатлы бала чагым минем,
Серле сәгать эзлим Сарайда.
Тавышы бар, әмма үзен тапмыйм,
Бәхет сәгатьләре соң кайда?

Тәүге кабат без икебез бергә
Серле сәгать чыңын ишеттек.
И курыктык күреп калырлар дип,
Нидер булыр төсле без көттек.

Серләр ачылыр да туктар төсле
Йөрүеннән сәгать телләре.
Йөрәк тибешеннән күтәрелде
Дәүләт сәгатенең герләре.

Тын да алмый, кулга-кул тотынып,
Без тыңлыйбыз сәгать тавышын.
Ә ул саный безнең бала чакның
Үтеп барган еллар агышын.

Сәгать йөри, Дәүләт сәгате бу,
Ак Сарайга каян килгән ул?
Тыпырчына йөрәк шомланудан,
Сәгать йөргән төсле тибә ул.

Уктай атылабыз урамга без,
Төсе качкан күзләр ялтырый.
Сүз әйтерлек хәл дә калмаган ич,
Тешләр тешкә тими калтырый.

## 7

Килеп бәреләбез Дәү әнигә.
Әйтерсең лә урлап тотылдык.
Йөзем комач төсле оялудан,
Кызалаклар төсле кызыллык.

Сакламадым серне, уртаклаштым,
Мин бит дәүләт серен чишкәнмен.
Болаңгырлы[1] куктәй күңелкәем,
Бәрәкәтләр китсә нишләрмен?

---

[1] Болаңгыр – болытлы, күңелсез.

– Дустыңның да дусты булыр, кызым,
Нишләдең син, балам, и җанаш?..
Үкенече – моңлы күзләрендә.
...Гомер буе сабак бу караш.

Сабыр гына аркабыздан сөйде,
Шуның белән бетте шелтәсе.
Сыя[1] суларыдай ташып акты
Күзләремнең яшьле элпәсе.

Без аңладык шунда ике сабый
Сер сакламас күңел тарлыгын.
Һәм бүгеннән башлап икебезгә
Уртак булган серләр барлыгын.

Без аңладык шушы мизгелләрдә
Сер саклауның олы бәһасен.
Җирдә тугры булып вәгъдәләргә
Сер ачкычын саклап яшисен.

Ак Сарай – ул олы сер сандыгы,
Ак Сарай – ул аклык өлгесе,
Ата-бабаларның үз Ватанын,
Туган җирен сөю билгесе.

Хан ярлыгы серен саклый Сарай,
Әманәтне үтәү – ышаныч.
Дәүләт сәгатенең чыңнарыннан
Ак Сарайга иңгән куаныч.

[1] Сыя – ташудагы элпә кар.

8

Шанлы туйлар барган бу Сарайда,
Алтын касәләрдән сыйланып.
Сукман[1] хаким кунак кабул иткән,
Батыр дуслар килгән җыйналып.

Аркыш[2] маллар, хәзинәләр төяп
Килгән монда ханнан илчеләр.
Чуралары[3] иккән мул уңыштан
Тәгам җыйган олы-кечеләр.

Мул тормышлы төзек дәүләт булган,
Дәүләт сәгатендә – бәрәкәт.
Дуслык, Шәфкать, Иман булган җир бу,
Илаһилык яши – мең рәхмәт!

Нигез эргәсендә басып торам,
Ак Сарайда күңел тәрәзәм.
Дәүләт сәгатенең чын кодрәтен
Сөйли миңа ыру шәҗәрәм.

## Югалган ачкыч

Ак Сарай ачкычын югалткан каенатам аны эзләргә киленнәргә кушты һәм табучыга төп нигезне бүләк итте.

*Дәү әнием Бибимәрьям истәлегеннән*

– Ак Сарайның җуйдым ачкычын,
Кем табалыр икән, эзләгез!
Табучыга мирас шушы нигез,
Соңра дәгъвалашып йөрмәгез.

---

[1] Сукман – батыр, дус.
[2] Аркыш – кәрван.
[3] Чура – игенче, бигә буйсынган кеше.

Зирәк бабам улларына түгел,
Киленнәргә кушкан бу эшне.
Мал булгәндә белә, улларына
Низаглашу бер дә килешми.

Таш баз өсте туфрак арасында
Ак Сарайның серле ачкычы.
Кайсы килен табар, кемгә булыр
Татлы минутларның ачысы?

Дүрт киленнең тик өчесе эзли,
Туфрак мамык төсле йомшаган.
– Белми кала Мәрьям, кайда йөри,
Ачкыч эзләргә ник чыкмаган?

Биек болдыр бер нурланып ала:
– Мин монда, – ди Мәрьям, – нәрсә бар?
– Ак Сарайның ачкычларын эзләш... –
Дәррәү аңлаталар хатыннар.

– Кем табалса, нигез шуңа, – диде,
Кайнатаның вәгъдә сүзе шул.
...Ялтырап китә ачкыч, туфракны
Бер сыпырып кына карый ул.

Ачкыч миндә, әти, кемгә бирим? –
Йөгереп килә Сарай янына.
– Нигез сезгә, кызым, вәгъдә – иман,
Һәм сез хуҗа йортым малына.

Ач Сарайны үз кулларың белән,
Кереп кара, муллык күрерсең.
Шиккә калган килен эчкә уза,
Нинди серләр барын кем белсен!

Сарай тып-тын, нигез диварында
Гасыр моңы сеңгән ак ташлар.
Бәхет ачкычымы кулларында,
Ни күрергә язган бу башлар?

Сарай түрләрендә бүлем-бүлем,
Тәгам-ризык, бөтен кирәге.
Авыл халкын ашлы иткән Сарай –
Тәлим[1] байлык – тормыш терәге.

Бу минуттан барысы да аңа,
Авыл язмышы да кулында.
Һич сынатмас, аклар өметләрне,
Мең киртәне җиңеп юлында.

## 10

Әллә йөрәк шулай ярсып тибә,
Сәгать йөргән төсле Сарайда.
Саташадыр, бәлки, сөенечтән,
Башы әйләнгән чак болай да.

Келт-келт тавыш килә салмак кына,
Йөрәк алай тибә алмый бит.
Куркуыннан гына үзен-үзе
Ул юатып шулай алдый бит.

Агарынып чыга ул Сарайдан
Һәм ачкычны суза атага.
– Сәгать йөри анда, сәер сәгать,
Юрамагыз сүзем хатага.

[1] Тәлим – күп.

Акыллы карт тик елмаеп куя:
– Дәүләт сәгате ул – шатлыкка.
Йорт хуҗасы сезне кабул иткән,
Сөйләп йөрмә шаулап халыкка.

Димәк, сезне үзенә иш күреп,
Варис итә нигез хуҗасы.
Сез булырсыз бай да, бәхетле дә,
Читләп узар дөнья нужасы.

Садрый мулла нигезе бу, балам,
Изге нигез, бай һәм дәүләтле.
Аның олпатлыгы, гыйлемлеге
Заманында дөнья шаулатты.

Дәва өчен кышын түбәнөйдә
Куражиләк белән сыйлады.
Гарип-горабаны терелтте ул,
Мохтаҗ мөэминнәрне зурлады.

11

## Еланнан котылу

Буар еланнардан котылу өчен, милләткә
Садрый мулла кебек зирәкләр кирәк.

*Сөнгатулла бабам фикере*

Авыру кызны китергәннәр берчак,
Кипкән-корган, үтми ризыгы.
Үлем көтеп ята җиләктәй кыз,
Сүнгән өмет, тормыш кызыгы.

– Мин урманда йоклап бер төш күрдем:
Сусавымны бастым су эчеп.
Шул сәгатьтән башлап янам-көям,
Китә җегәр, бетә дәрт-көчем.

Мулла әйтә:
– Сөтле табак кирәк.
Китерәләр нәкъ ул кушканча.
– Бар да яхшы булыр, сау уяныр...
Дога укып кызны йоклата.

Табактагы сөткә агу сала,
Кешеләрнең барсын чыгара.
Кыз йоклагач, сөтне эчәр өчен,
Тиеш елан эчтән чыгарга.

Ул чыкканда, күрми калалар гел,
Барча кеше йоклый изерәп.
Көтә-көтә карт та йокымсырый.
...Елан үз кодрәтен сиздерә.

Яшь кыз берни сизми, авызыннан
Буаз елан чыга сузылып.
Чәч толымы төсле күкрәгеннән
Ул идәнгә төшә шуышып.

Табактагы сөтне эчә башлый,
Садрый мулла кызны уята.
– Авыруның сере шушы, балам.
Саусыз итеп елан йоклата.

## 12

Агулы сөт, үлем угы булып,
Елан күкрәгенә кадала.
Әнә шулай кызны терелтә ул,
«Күрәзәче» дигән ат ала.

Шул еллардан бирле ияле йорт,
Гомер бакый олуг дәүләтле.
Бу нигезгә хәер-дога кылып,
Зекер әйтә Дәүләт сәгате.

## Кичерде

Әйләнәм дә кайтам бала чакка,
Серне чишкән ерак елларга.
Кулга-кул тотынган сабый дустым
Сердәш булып яши һаман да.

Хәтеремдә икенче көнне дә
Ак Сарайга кабат кергәнем.
Ишетмәдем Дәүләт сәгатенең
Сәгадәтләр теләп йөргәнен.

Юкка чыккан иде серле сәгать,
Үпкәләпме безгә киткән ул?
Шул югалту белән аваздаш күк,
Газиз татар халкым үткән юл.

Үкси-үкси еладым бу көнне,
Гаепләдем үзем барсына.
Бер кайтырмы Дәүләт сәгатебез?
...Әрнешләрдән йөрәк ярсый ла.

Солтанатлы Сөембикәне дә
Сатлыкҗаннар ятка саттылар.
Дәүләт сәгатьләре яшерелгән
Сарай капкаларын ачтылар.

Таркаттылар илне, талаттылар,
Ханбикәне тоткын иттеләр.
Дәүләт сәгатьләре зекер әйткән
Диварларның серен чиштеләр.

## 13

Алтын айлы ап-ак Сарайларга
Кызыл хачлар элеп куйдылар.
Татарларым, ыруларым минем,
Нәсел горурлыгын җуйдылар.

Ничә гасыр үтте башны иеп,
Бер югалган даннар тиз килми.
Җимерелде Болгар, Казан, Чаллы –
Сатылганны дәвер кичерми.

Көрәш мәйданнары батыр сорый –
Яулап алыр өчен бөтенлек.
Дәүләт сәгатьләре дөрес йөрсә,
Татарыма килер чын хөрлек.

Ак Сараем, минем халкым төсле
Җуйган иде Дәүләт сәгатен.
Бар гаепне мин үземдә күрдем
Һәм еладым бетеп тәкатем.

Кичерүен ихлас сорадым мин:
– Өмет акләрмын, – дип үтендем.
Ак Сарайга сарылып сулкылдадым.
Аһ, үкендем соң мин, үкендем.

Еллар үтте, олыгайдык без дә,
Менә торгач тормыш баскычын.
Сабый дустым кулларында хәзер
Дәүләт Сараеның ачкычы.

Сарай эргәсендә тагын икәү –
Ишетелә сәгать чылдыры.
Куллар-кулга бәйләнгән шул көнгә
Тоташтыра гомер чылбыры.

## 14

Тормыш дәрьясында кайнаганда,
Хәсрәт сулары да эчелде.
Дәүләт сәгатебез кире кайтты,
Ак Сараем безне кичерде.

Җир шарында бердәм татулыкта
Яшә халкым гореф-гадәте!
Ак Сарайның чал диварларыдай
Имин булсын Дәүләт сәгате!

Хан ярлыгы васыятен җиткер,
Буын белән буын тоташсын.
Түзек килеш, Дәүләт сәгатебез,
Безнең йөрәкләргә тоташ син!

Сәгать суккан саен берләш, татар!
Илгә иңсен бәхет-сәгадәт.
Серләр яшерелгән Ак Сарайда
Дәүләт теләп торсын бу сәгать,
Бәрәкәттә булсын һәр сәгать!

# Эчтәлек

Минем куллар – синең кулда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Мәхәббәттән тора бөтен нәрсә . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Тамчылар бүләк итәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Канатларда өмет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Соңгы кар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Мин яратам сине . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Бары сөю... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Алларыма алма салдың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Синең ярда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Үбим әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
«Өзелә үзәк...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Чүлдәге бер йотым су...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Мин сине кичерә алмыйм...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Кайтаваз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Тәнем белән түгел...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Икебез дә берни аңламыйча...» . . . . . . . . . . . . . . 15
«Нигә пыскып яшисең син...» . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Сине эзләдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Күңелеңдә урын алдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Язмышлар – дулкында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Һәркемнең үзенеке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Беләсеңме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Тышта суык бүген...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Алмалар коелды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Үзем белән үзем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Хыял бакчасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Күңелдә яз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23

Яз – халәтем . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Төнге тынлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Киңәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Юкка гына тырыштылар . . . . . . . . . . . . 25
«Бер сүздән дә күңел кайта икән...» . . . . . . 26
«Кайчакта кышлар да җылыта...» . . . . . . . . 26
Ялгышу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Белмәделәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Төнге күбәләк . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Юлда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Мөмкинме соң . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Көч бир миңа! . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Язмыш язылганча булсын . . . . . . . . . . . 32
Бәхетле буласым килә . . . . . . . . . . . . . 33
Карама елмайганга . . . . . . . . . . . . . . 33
Беркем кагылмаган . . . . . . . . . . . . . . 34
Парлы толымнар . . . . . . . . . . . . . . . 35
Кичермим... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Гомер атында . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Олы булып яшим . . . . . . . . . . . . . . . 38
Кагылмагыз яраларга! . . . . . . . . . . . . . 39
Яфрак яңгырлары . . . . . . . . . . . . . . . 40
Җанымның сафлыгын алыштырмыйм... . . . . 40
Кыр казлары хушлашуы . . . . . . . . . . . . 41
Сорау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Таныш түгел җирдә танышлар . . . . . . . . . 42
Соңгы дәрес . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Вокзал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
«Мин юлларга чыгам сине уйлап...» . . . . . . 44
Хәерле юл сезгә! . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Чыршы зары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Туган як бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Барысын да кичерәбез . . . . . . . . . . . . . 48
Туган көнеңә . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Яңа елның тулган ае . . . . . . . . . . . . . . 50
Чулманда таң туа . . . . . . . . . . . . . . . 51

Һаман бер сорау . . . . . . . . . . . . . . . 52
Сагынам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Туганнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
«Бүген әле сине төштә күрдем...» . . . . . . . . . 54
Кирәмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Хәтерлиләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Җир – ул бер генә . . . . . . . . . . . . . . . 57
Туган җир генә . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Игенче хезмәте . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Мең яшәче, әни! . . . . . . . . . . . . . . . 60
Еллар сынаса да... . . . . . . . . . . . . . . 61
Әни . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Янәшәмдә Тукай . . . . . . . . . . . . . . . 63
Болар – сезнең, минем газизләрем . . . . . . . 64
И хатын-кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Имәннәр баш ия . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Безнең егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Вәзыйхка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Гаффарлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Йолдыз төсле . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Алтын туйда . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Ак яулыклы күрше әби . . . . . . . . . . . . . 71
Урман кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Солтан булды Солтан егете . . . . . . . . . . . 73
Йөрәгендә гаван уе . . . . . . . . . . . . . . 74
Туй теләкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Мактану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Комьютер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Куәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Ак Сарайда серләр бар *(Поэма)* . . . . . . . . 77

Литературно-художественное издание

*Гарифуллина Расимя Ахметзакировна*

**Рука об руку**

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Т.В.Пашагина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.10.2005.
Форматы $70\times90^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 3,51. Шартлы буяу-оттиск 3,80.
Нәшер-хисап табагы 3,13. Тиражы 2000 экз. Заказ А-814.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
ГУП Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

АAЖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.